ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.04.2026 Олы Кайбыч ав. № 196

Кайбыч муниципаль районында 2025-2026 еллар ягу сезоны тәмамлану һәм 2026-2027 еллар көзге-кышкы ягу чорына әзерләнү турында

РФ Хөкүмәтенең «Милекче һәм кулланучыларга күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары нигезендә һәм торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләрен, уртача тәүлеклек тышкы һава температурасы Цельсий буенча 8 градустан югарырак урнашу сәбәпле, ягулык-энергетик комплекс һәм социаль мәдәни көнкүреш объектларын 2026-2027 еллар көзге-кышкы ягу чорына вакытында һәм сыйфатлы әзерләү максатында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайбыч муниципаль районының социаль объектларын, торак фондын һәм башка кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүче предприятиеләргә һәм оешмаларга тәкъдим итәргә:

1.1. 2025 - 2026 еллар ягулык сезонын 2026 елның 20 апреленнән тәмамларга.

1.2. Пар казаны биналарында, үзәк җылылык пунктларында, җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итүнең тышкы челтәрендә һәм эчке инженер системаларында объектларны көзге-кышкы ягу чорына әзерләү чаралары нигезендә ремонтлау һәм профилактика эшләрен башларга.

2. Объектларны 2026 - 2027 елларның көзге-кышкы чорына әзерләүне 2027 елның 15 сентябренә төгәлләргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Е.Г. Давыдовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров